КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 31 октябрь г.Казань № 979

Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларының хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә акчалата түләүләрне билгеләү турында

Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физик культура спорт оешмаларының яшь белгечләренә – хезмәткәрләренә дәүләт ярдәме күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура-спорт оешмаларында эшләүче, аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы спорт министрлыгы гамәлгә ашыра торган, Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура-спорт оешмалары хезмәткәрләренә – яшь белгечләргә түбәндәге акчалата түләүләр билгеләргә:

эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә 1111 сум күләмендә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү, әмма аена 1111 сумнан да артык түгел;

хуҗалык төзеклəндерүгә бер тапкыр бирелә торган 20 000 сум күләмендә акчалата түләү.

2. Kapарга теркәлгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы, гамәлгә куючы функцияләре һәм вәкаләтләре Татарстан Республикасы спорт министрлыгы тарафыннан гамәлгә куелучы Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура – спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә акчалата түләүләр бирү тәртибе;

Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә әлеге карарның 1 пункты белән расланган күләмнәрдә акчалата түләүләрне билгеләп, Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар акчалары исәбеннән акчалата түләүләр бирү тәртибен эшләргә һәм расларга тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы, гамәлгә куючының функцияләре һәм вәкаләтләре Татарстан Республикасы спорт министрлыгы башкара торган, физик культура оешмаларының хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү билгеләү турында» 2018 ел, 29 декабрь, 1259 нчы карары үз көчен югалткан дип санарга.

5. Әлеге карар, әлеге карарның 6 пунктында күрсәтелгән нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

6. Әлеге карар, Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы, гамәлгә куючы функцияләре һәм вәкаләтләре Татарстан Республикасы спорт министрлыгы тарафыннан гамәлгә куелучы Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура – спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә акчалата түләүләр бирү тәртибе, Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе нигезләмәләре 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин